«РАСЛЫЙМ»

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры

__________ Э.Н. Фәттахов

"___"__________ 2016 нчы ел

# ТАТАР ТЕЛЕ

## Рус телендә гомуми белем бирүче оешмаларның татар төркемнәрендәге IX сыйныф укучыларына татар теленнән бердәм республика тестын үткәрү материалларының күрсәтмә варианты

**Рус телендә гомуми белем бирүче оешмаларның татар төркемнәрендәге IX сыйныф укучыларына татар теленнән бердәм республика тестын үткәрү материалларының күрсәтмә вариантына аңлатмалар**

2017 нче елгы бердәм республика тестын үткәрү материалларының күрсәтмә варианты белән танышканда, шуны истә тотыгыз: тәкъдим ителгән биремнәр 2017 нче елда тест үткәрү материалларының вариантлары ярдәмендә тикшереләчәк эчтәлекнең барлык элементларын чагылдырмый. 2017 нче елгы бердәм республика тестында тикшерелергә мөмкин булган эчтәлек элементларының тулы исемлеге рус телендә урта гомуми белем бирүче оешмаларның татар төркемнәрендәге IX сыйныф укучылары өчен бердәм республика тестына әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр һәм эчтәлек элементларының кодификаторында тәкъдим ителгән.

Күрсәтмә вариант катнашучыга һәм киң җәмәгатьчелеккә бердәм республика тесты материалларының структурасы, биремнәр саны, аларның формасы, катлаулылык дәрәҗәсе турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә. Бу варианттагы киңәйтелгән җавап бирүне таләп иткән биремнәрне үтәүнең бәяләү критерийлары җавапның тулылыгы һәм дөрес язылышы таләпләре турында күзаллау тудыра.

Күрсәтмә вариант материаллары чыгарылыш сыйныф укучыларында бердәм республика тестына әзерлек осталыгын булдырачак.

# Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендәге IX сыйныф укучыларына ТАТАР ТЕЛЕННӘН бердәм республика тесты

## Демоверсия

### Эшне башкару өчен күрсәтмә

Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының 9 нчы сыйныфын тәмамлаучы укучылар өчен, татар теленнән бердәм республика тестына 2 сәгать 30 минут (150 минут) вакыт бирелә. Тест биремнәре 2 бүлектән тора.

**Беренче бүлек** 20 биремне (1–20) үз эченә ала. Алар укылган текст нигезендә эшләнә. 1-2 нче биремнәрне үтәгәндә, дөрес җавапны тәкъдим ителгән 4 варианттан сайлап алып, 1 нче номерлы җавап бланкына бер цифр белән язарга кирәк. 3-20 нче биремнәргә җавапларны укучылар мөстәкыйль рәвештә формалаштыралар. Әлеге биремнәргә җаваплар сүз (сүзтезмә) яки цифрлар белән 1 нче номерлы җавап бланкына языла. Ялгышкан очракта, аны пөхтә итеп сызып, янына дөрес җавапны язарга була.

**Икенче бүлектәге** биремне укучылар 1 нче бүлектәге текст буенча башкаралар. Эшли башлаганчы, тәкъдим ителгән (21.1 һәм 21.2) биремнәрнең берсен сайларга һәм үз фикереңне дәлилләп, эзлекле рәвештә киңәйтелгән җавап бирергә кирәк. Әлеге бирем 2 нче номерлы җавап бланкында эшләнә.

Тест биремнәрен үтәгәндә, орфографик сүзлекләрдән файдаланырга рөхсәт ителә.

Караламадагы язулар тикшерелми!

Биремнәрне тәкъдим ителгән эзлеклелектә эшләргә киңәш ителә. Җавап бирергә авырсынган бирем очраса, аны калдырып, башкаларын эшли торыгыз. Вакыт калса, аларга яңадан әйләнеп кайтырсыз.

Үтәлгән биремнәр өчен куелган баллар бергә кушыла. Мөмкин кадәр күбрәк биремгә дөрес җавап биреп, югарырак балл җыярга тырышыгыз.

**Сезгә уңышлар телибез!**

## I бүлек

***Текстны укыгыз һәм 1-20 нче биремнәрне үтәгез.***

### Канатлы ай

(1) Кич. (2) Авыл тынлык куелыгына чумган. (3) Үзе шундый җылы һәм рәхәт. (4) Өйгә һич керәсе килми. (5) Капка төбендәге утыргычта, кичке шәфәкъ матурлыгына хозурланып, әнисе белән нәни кыз Фирая сөйләшеп утыралар. (6) Утыралар дигәч тә, утыргычта әнисе генә утыра, ә Фирая аның итәгенә менеп кунаклаган.

(7) Күк гөмбәзендә, учлап сибелгән энҗе-мәрҗәннәрдәй, йолдызлар җемелди.

(8) Аларның барысын да уздырып, түм-түгәрәк ай көмештәй нурларын җиргә сибә, гүя ул шулай Фираяны сөеп елмая. (9) Айның ике ягында да аккош канатларыдай, нәфис каурый болытлар йөзеп йөри. (10) Тулган, менә-менә канатланып очып китәрдәй тоела. (11) Әнисенең итәгендә иркәләнеп утырган Фирая да, әлеге сихри күренештән әсәрләнеп, соклану тулган күзләрен күк гөмбәзеннән ала алмый.

(12) — Әнием, кара әле! (13) Кара... әнә анда, күктә, аккоштай ак канатлы ай йөзә. (14) Канатлы ай!..

(15) Әнисе дә айга карый.

(16) — И-и-и кызым, рәхмәт төшкере! (17) Искиткеч нурлы икән шул кичке ай. (18) Гаҗәп икән. (19) Кызлар шикелле елмая. (20) Гомеремдә дә мондый айны күргәнем юк иде. (21) Бәхеткә генә була күрсен мондый хозур, мондый матур күренеш, <…> дип, үз нәүбәтендә хыялый, күбәләктәй канатланган нәни кызына карап, нурлы айдай елмая.

(22) Әйе шул, әниләр янында ай да канатлы.

*(Н.Каштанов*)*

****Нәкыйп Фәсхетдин улы Каштанов*** (1942) – язучы, шагыйрь, журналист. Язучының мәхәббәт, яшәү, язмыш, яшьлек темаларына караган хикәяләре татар прозасының матур үрнәкләре булып санала. Аларда кешелеклелек, явызлык, саранлык,

гадел һәм ярдәмчел булу кебек уңай һәм тискәре сыйфатлар төрле геройлар мисалында ачыла. Хикәяләр укучыны кешелек кыйммәтләре хакында уйланырга мәҗбүр итә.



***1–20 нче биремнәрне укылган текст нигезендә башкарыгыз. Җавапларны сүз (сүзтезмә) яки цифрлар белән языгыз. Һәр хәреф яки цифр аерым шакмакка язылырга тиеш. Сүзләр яки цифрлар, санап үтелгәндә, <u>буш урынсыз, өтерсез һәм башка билгеләрсез</u> языла. Җавапларны язганда, буш шакмаклар калдырырга ярамый.***

1 Кайсы мәгълүмат түбәндәге сорауга җавап була ала?
***Фирая ни өчен айны канатлы дип атый?***
1) Чөнки ай көмештәй нурларын җиргә сибә.
2) Чөнки айның ике ягында болытлар йөзә.
3) Чөнки ай кызлар шикелле елмая.
4) Чөнки ай Фираяны сөеп елмая.
Җавап: ___________________________.

2 **Метафора** булган җөмләне табыгыз.
1) Авыл тынлык куелыгына чумган.
2) Өйгә һич керәсе килми.
3) Әнием, кара әле!
4) Әнисе дә айга карый.
Җавап: ___________________________.

3 6 нчы җөмләдәге **әйтелеше язылышына** туры килмәгән сүзне языгыз.
Җавап: ___________________________.

4 16 нчы җөмләдәге **әйтелеше язылышына** туры килмәгән сүзне языгыз.
Җавап: ___________________________.

5 5 нче җөмләдән **«кечкенә»** сүзенә **синоним** булган сүзне табып языгыз.
Җавап: ___________________________.

6 2 нче җөмләдән **баш кисәкләрне** табып языгыз.
Җавап: ___________________________.

7 1-4 нче җөмләләр арасыннан **тиңдәш кисәкләр** булган җөмләнең номерын языгыз.
Җавап: ___________________________.

8 13-15 нче җөмләләр арасыннан **тойгылы җөмләнең** номерын языгыз.
Җавап: ___________________________.

**9**

**Аерымланган хәлгә** бәйле куелган тыныш билгеләренең номерларын языгыз. *Аларның барысын да уздырып, (1) түм-түгәрәк ай көмештәй нурларын җиргә сибә, (2) гүя ул шулай Фираяны сөеп елмая. (3)*
Җавап: ______________________________.

**10**

**Эндәш сүзгә** бәйле куелган тыныш билгесенең номерын языгыз.
*(1) — Әнием, (2) кара әле! (3) Кара... (4) әнә анда, (5) күктә, (6) аккоштай ак канатлы ай йөзә. (7)*
Җавап: ______________________________.

**11**

8 нче җөмләдә ничә **гади җөмлә** бар? Җавапны сан белән языгыз.
Җавап: ______________________________.

**12**

21 нче җөмләдә <…> тамгасы урынына кайсы **тыныш билгесе** куелырга тиеш? Җавапны сүз белән языгыз.
Җавап: ______________________________.

**13**

4-6 нчы җөмләләр арасыннан **бер составлы җөмләнең** номерын языгыз.
Җавап: ______________________________.

**14**

**Туры сөйләмгә** бәйле куелган тыныш билгесенең номерын языгыз.
*(1) — И-и-и кызым, (2) рәхмәт төшкере! (3)*
Җавап:______________________________.

**15**

9 нчы җөмләдән **«тупас»** сүзенә **антоним** булган берәмлекне табып языгыз.
Җавап:______________________________.

**16**

19 нчы җөмләдән **бәйлекне** табып языгыз.
Җавап: ______________________________.

**17**

Калын хәрефләр белән бирелгән **фигыльнең төрен** языгыз.
*Күк гөмбәзендә, учлап* ***сибелгән*** *энҗе-мәрҗәннәрдәй, йолдызлар җемелди.*
Җавап: ______________________________.

**18**

13 нче җөмләдән **ясалма рәвешне** табып языгыз.
Җавап: ______________________________.

**19**

7 нче җөмләдән [ы] авазы [о]лашып әйтелә торган сүзне табып языгыз.
Җавап: ______________________________.

**20** 11 нче җөмләдән **иялек килеше** кушымчасы ярдәмендә бәйләнгән сүзтезмәне табып языгыз.

Җавап: ______________________________.

***Барлык җавапларны, тестны үтәү өчен күрсәтмәдә әйтелгән тәртиптә, 1 нче номерлы бланкка күчереп язарга онытмагыз.***

## II бүлек

***Укылган текстны файдаланып, 21.1 яки 21.2 БИРЕМНӘРЕНЕҢ БАРЫ ТИК БЕРСЕН ГЕНӘ үтәгез. Әлеге биремнең җавабын 2 нче номерлы җаваплар бланкына языгыз. Яза башлар алдыннан сайланган биремнең номерын күрсәтегез.***

**21.1** **Әйе шул, әниләр янында ай да канатлы.**

Текст ахырында китерелгән бу сүзләрнең мәгънәсен аңлатып, сочинение языгыз.

Укылган тексттан фикерләрегезне раслый торган **2 дәлил** китерегез. Мисаллар биргәндә, кирәкле җөмләләрне языгыз яисә аларның номерларын күрсәтегез.

Сочинениенең күләме **100 сүздән ким** булмаска тиеш. Сочинениене пөхтә һәм аңлаешлы итеп языгыз.

**21.2** **ӘНИ** сүзен ничек аңлыйсыз? Үзегез формалаштырган билгеләмәне дәлилләгез. Үзегез язган билгеләмәне тезис итеп алып, **«Әнием»** дигән темага сочинение языгыз. Тезисыгызны раслый торган **2 дәлил** китерегез: дәлилнең берсен укылган тексттан алыгыз, икенчесен тормыш тәҗрибәгездән чыгып формалаштырыгыз.

Сочинениенең күләме **100 сүздән ким** булмаска тиеш. Сочинениене пөхтә һәм аңлаешлы итеп языгыз.

## Татар теле буенча бердәм республика тестын бәяләү системасы

### 1 нче бүлек

### 1-20 нче биремнәрне тикшерү

Бердәм республика тестының 1-20 нче биремнәрен **дөрес** үтәгән өчен, һәр биремгә – 1 балл, **җавап хаталы булса** яки **бөтенләй булмаса,** 0 балл куела.

*1 нче таблица*

| **Биремнең номеры** | **Дөрес җавап** |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 2 | 1 |
| 3 | Фирая |
| 4 | төшкере |
| 5 | нәни |
| 6 | авыл чумган |
| 7 | 3 |
| 8 | 14 |
| 9 | 1 |
| 10 | 2 |
| 11 | 2 |
| 12 | сызык |
| 13 | 4 |
| 14 | 1 |
| 15 | нәфис |
| 16 | шикелле |
| 17 | сыйфат яки сыйфат фигыль |
| 18 | аккоштай |
| 19 | йолдызлар |
| 20 | әнисенең итәгендә |

## 2 нче бүлек
## 21.1 биремен тикшерү критерийлары

21.1 биремендә җавап түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә.

*2 нче таблица*

| № | Текст эчтәлеген анализлауга бәйле темага язылган сочинениене (21.1) бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| **С1К1** | **Тексттан алынган кисәкнең мәгънәсен аңлау** | |
| | Укучы тексттан алынган кисәкнең эчтәлеген дөрес аңлаткан. Аңлатмада хаталар юк. | 2 |
| | Укучы тексттан алынган кисәкнең эчтәлеген гомумән дөрес аңлаткан,<br>**ләкин**<br>аңлатмада 1 хата бар. | 1 |
| | Укучы тексттан алынган кисәкнең эчтәлеген дөрес аңлатмаган<br>**яки**<br>укучы, тексттан алынган кисәкнең эчтәлеген аңлатканда, 2 яки күбрәк хата ясаган<br>**яки**<br>тексттан алынган кисәк эчтәлегенең аңлатмасы язма эштә юк. | 0 |
| **С1К2** | **Дәлил-мисал (-лар) ның булуы** | |
| | Укучы тексттан әлеге кисәкнең эчтәлегенә туры килә торган 2 дәлил-мисал китергән. | 3 |
| | Укучы тексттан әлеге кисәкнең эчтәлегенә туры килә торган 1 дәлил-мисал китергән. | 2 |
| | Укучы башка тексттан дәлил-мисал (-лар) китергән. | 1 |
| | Укучы әлеге кисәкнең эчтәлеген аңлата торган дәлил-мисал (-лар) китермәгән<br>**яки**<br>укучы биремдәге цитатаны я аның бер өлешен дәлил-мисал (-лар) итеп китергән. | 0 |
| **С1К3** | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле булуы, язу эзлеклелеге** | |
| | Укучының эше мәгънәви бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле булуы һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| | Укучының эше мәгънәви бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле булуы һәм эзлеклелек белән характерлана,<br>**ләкин**<br>1 логик хата бар,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә 1 урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин**<br>логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә 2 урында хата бар. | 0 |
| **С1К4** | **Эшнең композицион бөтенлеге** | |
| | Эш композицион яктан бөтен һәм тәгәлләнгән, текст төзүдә хаталар юк. | 2 |
| | Эш композицион яктан бөтен һәм тәгәлләнгән,<br>**ләкин**<br>текст төзүдә 1 хата бар. | 1 |
| | Текст төзүдә 2 яки күбрәк хата бар. | 0 |
| | **С1К1-С1К4 критерийлары буенча сочинение өчен иң югары балл** | **9** |

Игътибар!

Әгәр сочинениедә текст күчереп кенә язылса яки анда текстның эчтәлеге генә чагылыш тапса, бәяләүнең барлык критерийлары буенча (С1К2-С1К4) 0 балл белән бәяләнә.

**Язма эшнең грамоталылыгы һәм аның фактик тәгәллеге** аерым бәяләнә (4 нче таблицаны кара).

*3 нче таблица*

| № | Текст эчтәлеген анализлауга бәйле темага язылган сочинениене (21.2) бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| **С2К1** | **Төшенчәнең мәгънәсен аңлату** | |
| | Укучы (сочинениенең теләсә кайсы өлешендә теге яки бу формада) төшенчәгә билгеләмә биргән һәм аңлаткан. | 2 |
| | Укучы (сочинениенең теләсә кайсы өлешендә теге яки бу формада) төшенчәгә билгеләмә биргән,<br>**ләкин**<br>аңлатмаган. | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | Укучы төшенчәгә дөрес билгеләмә бирмәгән<br>**яки**<br>укучынең эшендә төшенчә аңлатылмаган. | 0 |
| **С2К2** | **Дәлил-мисалларның булуы** | |
| | Укучы 2 дәлил-мисал китергән: берсе – текстран, икенчесе тормыш тәҗрибәсеннән алынган<br>**яки**<br>укучы укылган текстран 2 дәлил-мисал китергән. | 3 |
| | Укучы укылган текстран 1 дәлил-мисал китергән. | 2 |
| | Укучы тормыш тәҗрибәсеннән дәлил-мисаллар (-лар) китергән. | 1 |
| | Укучы дәлил-мисал китермәгән. | 0 |
| **С2К3** | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле булуы, язу эзлеклелеге** | |
| | Укучының эше мәгънәви бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле булуы һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |
| | Укучының эше мәгънәви бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле булуы һәм эзлеклелек белән характерлана,<br>**ләкин**<br>1 логик хата бар,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә 1 урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин**<br>логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә 2 урында хата бар. | 0 |
| **С2К4** | **Эшнең композицион бөтенлеге** | |
| | Эш композицион яктан бөтен һәм төгәлләнгән, текст төзүдә хаталар юк. | 2 |
| | Эш композицион яктан бөтен һәм төгәлләнгән,<br>**ләкин**<br>текст төзүдә 1 хата бар. | 1 |
| | Текст төзүдә 2 яки күбрәк хата бар. | 0 |
| **С2К1-С2К4 критерийлары буенча сочинение өчен иң югары балл** | | **9** |

Игътибар!

Әгәр сочинениедә текст күчереп кенә язылса яки анда текстның эчтәлеге генә чагылыш тапса, бәяләүнең барлык критерийлары буенча (С2К1-С2К4) 0 балл белән бәяләнә.

**Язма эшнең грамоталылыгы һәм аның фактик төгәллеге** аерым бәяләнә (4 нче таблицаны кара).

*4 нче таблица*

| № | Укучы сөйләменең грамоталылыгын һәм фактик төгәллеген бәяләү критерийлары | |
|---|---|---|
| **ГК1** | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфографик хаталар юк **яки** хата 1 дән артык түгел | 2 |
| | 2-3 хата җибәрелгән | 1 |
| | Хаталарның саны 4 тән артык | 0 |
| **ГК2** | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталар юк **яки** хаталар 2 дән артык түгел | 2 |
| | 3-4 хата бар | 1 |
| | Хаталарның саны 5 тән артык | 0 |
| **ГК3** | **Грамматик нормаларның үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталар юк **яки** 1 хата бар | 2 |
| | 2 хата бар | 1 |
| | Хаталарның саны 3 тән артык | 0 |
| **ГК4** | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләм хаталары юк **яки** хата 2 дән артык түгел | 2 |
| | 3–4 хата бар | 1 |
| | Хаталарның саны 5 тән артык | 0 |
| **ФК1** | **Язма сөйләмнең фактик төгәллеге** | |
| | Материалны язмада бирүдә, шулай ук аңлауда һәм терминнар кулланылышында фактик хаталар юк | 2 |
| | Материалны язмада бирүдә яки терминнар кулланылышында 1 хата бар | 1 |
| | Материалны язмада бирүдә яки терминнар кулланылышында 2 хата бар | 0 |
| **ГК1-ГК4, ФК1 критерийлары буенча сочинение өчен иң югары балл** | | **10** |

Грамоталылыкны бәяләгәндә (ГК1–ГК4), **сочинениенең күләмен** истә тотарга кирәк.

4 нче таблицада бирелгән нормативлар сочинениедә 100 һәм күбрәк сүз булган очракта тәкъдим ителә.

Әгәр сочинениедә 50-99 сүз булса, ГК1–ГК4 критерийлары буенча 1 дән артык балл куелмый.

ГК1 – орфографик хаталар булмаса яки тупас булмаган бер хата булса, 1 балл куела.

ГК2 – пунктуацион хаталар булмаса яки тупас булмаган бер хата булса, 1 балл куела.

ГК3 – грамматик хаталар булмаса, 1 балл куела.

ГК4 – сөйләм хаталары булмаса, 1 балл куела.

Әгәр сочинение 50 сүздән дә кимрәк булса, ГК1–ГК4 критерийлары буенча мондый эш 0 балл белән бәяләнә.

Барлык эш өчен, укучы ала алган **иң югары балл – 39.**

**БРТ эше өчен түбәндәге билгеләр куела:**

0-14 балл – «2» ле билгесе;

15-24 балл – «3» ле билгесе;

25-33 балл – «4» ле билгесе. Искәрмә: бу очракта укучы грамоталылык өчен (ГК1–ГК4 критерийлары) 4 баллдан кимрәк балл җыймаска тиеш. Әгәр укучы ГК1–ГК4 критерийлары буенча 4 баллдан кимрәк балл җыйса, «3» ле билгесе куела.

34-39 балл – «5» ле билгесе. Искәрмә: бу очракта укучы грамоталылык өчен (ГК1–ГК4 критерийлары) 6 баллдан кимрәк балл җыймаска тиеш. Әгәр укучы ГК1–ГК4 критерийлары буенча 6 баллдан кимрәк балл җыйса, «4» ле билгесе куела.